РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Масягутовского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Дружба, д. 12. Азнакаевский район,
с.Масягутово, 423321,
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авыл җирлеге
башлыгы

Дружба ур., 12 йорт, Азнакай районы, Мәсгут
авылы, 423321
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«07» ноября 2023 ел.** **№5**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгүт авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районының Мәсгүт авыл җирлеге Уставының 15.1 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәсгүт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авылы җирлеге Яхшы-Бай торак пунктында Урман урамы адресы буенча урнашкан Яхшы-Бай торак пунктында сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2023 елның 24 ноябренә 17 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсъәләне түбәндәгечә расларга:

"Сез 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә, башкалар өчен 500 сум күләмендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән үзара салым кертүгә ризамы:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авылы җирлеге Яхшы-Бай торак пунктындагы зиратта агачларны кисәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны, кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә, Мәсгүт авылы жирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Д.З. Миннеханов